**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
Балыклы-Чукаевского **СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422655, с.Балыклы-Чукаево,
ул. Центральная, дом 9

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАЛЫКЛЫ ЧҮКӘЙ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422655, Балыклы Чүкәй авылы
Үзәк урам, 9 нчы йорт,

Тел.: (84361) 26357, факс: (84361) 26357, e-mail:blc,rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.10.2019 Балыклы Чүкәй ав. № 24

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы Чүкәй авыл жирлегенең Балыклы Чүкәй, Иске Арыш, Керәшен Казысы авыл торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге ”Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 45-ЗРТ номерлы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Балыклы Чүкәй авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы Чүкәй авыл җирлегенең Балыклы Чүкәй авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2019 елның 29 октябрендә 9 сәг. 00 минутка билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы Чүкәй авыл җирлегенең Керәшен Казысы авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2019 елның 29 октябрендә 13 сәг. 00 минутка билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы Чүкәй авыл җирлегенең Иске Арыш авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2019 елның 30 октябрендә 9 сәг. 00 минутка билгеләргә.
4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы Чүкәй авыл җирлегенең Балыклы Чүкәй авыл торак пунктында үзара

салым кертү буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2019 елның 31 октябрендә 13 сәг. 00 минутка билгеләргә.

5. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы Чүкәй авыл җирлегенең Иске Арыш авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2019 елның 31 октябрендә 9 сәг. 00 минутка билгеләргә. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта көн итүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

6. Гражданнар җыены каравына куела торган сорауны расларга:

Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы Чүкәй авыл җирлегенең Балыклы Чүкәй, Керәшен Казысы, Иске Арыш авыл торак пунктларында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 300 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- Балыклы Чүкәй һәм Иске Арыш авылларында юллар ремонты өчен вакланган таш сатып алуга;

- транспорт хезмәтләренә түләүгә;

- кышкы чорда Балыклы Чүкәй, Керәшен Казысы, Иске Арыш авылларында урамнарның йөри тоган өлешләрен карап (кардан чистартып) торуга:

“ЯКЛЫЙМ” “КАРШЫ”

5. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң өч көн эчендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы Чүкәй авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга:

Балыклы Чүкәй авылы, Үзәк урам, 8 йорт; Иске Арыш авылы, Үзәк урам, 23А йорт; Керәшен Казысы авылы, Титов урамы, 11Б йорт;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда.

6. Карар басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Балыклы Чүкәй авыл җирлеге башлыгы А.М.Нуртдинова